КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 декабрь г.Казань № 1721

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 26 сентябрь, 464 нче; 2005 ел, 1 ноябрь, 517 нче; 2005 ел, 29 декабрь, 661 нче; 2006 ел, 1 март, 87 нче; 2006 ел, 21 апрель, 198 нче; 2006 ел, 9 июнь, 293 нче; 2007 ел, 18 май, 196 нчы; 2008 ел, 15 июль, 509 нчы; 2009 ел, 5 июнь, 360 нчы; 2009 ел, 17 август, 551 нче; 2010 ел, 8 июнь, 440 нчы; 2010 ел, 14 октябрь, 808 нче; 2010 ел, 2 декабрь, 976 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 7 октябрь, 838 нче; 2011 ел, 15 ноябрь, 935 нче; 2012 ел, 22 август, 726 нчы; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2013 ел, 18 февраль, 110 нчы; 2013 ел, 7 март, 152 нче; 2013 ел, 27 апрель, 286 нчы; 2013 ел, 10 август, 558 нче; 2014 ел, 21 апрель, 261 нче; 2015 ел, 1 июнь, 397 нче; 2016 ел, 10 октябрь, 733 нче; 2016 ел, 13 декабрь, 925 нче; 2017 ел, 6 март, 127 нче; 2017 ел, 26 май, 309 нчы; 2017 ел, 14 ноябрь, 867 нче; 2018 ел, 4 июль, 545 нче; 2018 ел, 24 июль, 586 нчы; 2018 ел, 10 декабрь, 1107 нче; 2018 ел, 14 декабрь, 1135 нче; 2019 ел, 16 апрель, 301 нче; 2019 ел, 21 май, 416 нчы; 2019 ел, 15 июнь, 493 нче; 2019 ел, 13 июль, 576 нчы; 2019 ел, 12 октябрь, 907 нче; 2020 ел, 10 февраль, 83 нче; 2020 ел, 18 май, 400 нче; 2020 ел, 28 май, 436 нчы; 2020 ел, 13 июль, 577 нче; 2020 ел, 10 октябрь, 917 нче; 2020 ел, 27 октябрь, 962 нче; 2020 ел, 2 декабрь, 1087 нче; 2021 ел, 31 август, 790 нчы; 2022 ел, 1 апрель, 306 нчы; 2022 ел, 16 июнь, 567 нче; 2022 ел, 22 декабрь, 1395 нче; 2023 ел, 10 гыйнвар,

2 нче; 2023 ел, 6 март, 221 нче; 2023 ел, 2 июнь, 676 нчы; 2023 ел, 10 октябрь, 1292 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы хезмәткәрләренең иң чик санын түбәндәгечә билгеләргә:

аппарат буенча – вазыйфаи окладлары буенча 4 679,472 мең сум күләмендәге айлык хезмәт өчен түләү фонды белән 186 берәмлек;

территориаль органнар буенча – вазыйфаи окладлары буенча 1 094,989 мең сум күләмендәге айлык хезмәт өчен түләү фонды белән 67 берәмлек.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының территориаль органнарындагы штат санын кушымта нигезендә 67 берәмлек итеп расларга.»;

6 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Министрлык үз эшчәнлеген территориаль органнарда турыдан-туры һәм алар һәм Министрлыкның ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләре аша гамәлгә ашыра.»;

3.3 пунктта:

3.3.1 пунктчада:

унтугызынчы абзацта «мәгълүмат ресурслары» сүзләре алдына «территориаль органнарның» сүзләрен өстәргә;

утыз беренче абзацта «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм күрсәтү фонды – дәүләт корпорациясе» сүзләрен «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе» сүзләренә алмаштырырга;

кырык алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлыкта, аның территориаль органнарында һәм ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләрендә Татарстан Республикасы милке булган һәм Министрлык белән аның ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләренә оператив идарә хокукында беркетелгән объектларның (территорияләрнең) террорчылыктан саклануга карата таләпләрне үтәүне оештыра һәм тәэмин итә;»;

түбәндәге эчтәлекле $3.3.3^1$ пунктча өстәргә:

«$3.3.3^1$. «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә яңадан бүленгән вәкаләтләр өлкәсендә:

1) җирлекнең җирле үзидарә органнарының шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге түбәндәге вәкаләтләрен гамәлгә ашыра:

генераль план проектын әзерләү турында карар, шулай ук генераль планга үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерләү турында карар кабул итү;

генераль план проектын әзерләү, генераль планны раслау, шул исәптән генераль планга үзгәрешләр кертү;

территориаль планлаштыруның һәм шәһәр төзелешен зоналаштыруның бердәм документын әзерләү һәм раслау, шул исәптән мондый бердәм документка үзгәрешләр кертү;

җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү турында, шулай ук җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында яисә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәрне кире кагу турында проектны әзерләү хакында карар кабул итү;

җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау, шул исәптән җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү;

шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү һәм раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү, шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен билгеләү;

җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында йә мондый рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү;

рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә йә мондый рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү;

территорияне планлаштыру документларын әзерләү турында карар кабул итү;

территорияне планлаштыру документларын әзерләүне тәэмин итү, территорияне планлаштыру документларын раслау, шул исәптән территорияне планлаштыру документларына үзгәрешләр кертү;

җирлек территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә объектлар төзелешенә, аларны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү;

җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү, теркәү һәм бирү;

территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул итү һәм гамәлгә ашыру;

җир кишәрлекләренә һәм (яисә) аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларына хокук ияләре инициативасы буенча гамәлгә ашырыла торган территорияне комплекслы үстерү турында шартнамәләр төзү;

2) муниципаль районның җирле үзидарә органнарының шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге түбәндәге вәкаләтләрен гамәлгә ашыра:

муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасын әзерләү турында карар, шулай ук мондый схемага үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерләү хакында карар кабул итү;

муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасы проектын әзерләү, муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасын раслау, шул исәптән мондый схемага үзгәрешләр кертү;

шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү һәм раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү, шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен билгеләү;

территорияне планлаштыру документларын әзерләү турында карар кабул итү;

территорияне планлаштыру документларын әзерләүне тәэмин итү, территорияне планлаштыру документларын раслау, шул исәптән территорияне планлаштыру документларына үзгәрешләр кертү;

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә яңадан бүленгән Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системасы вәкаләтләрен алып бару һәм мондый дәүләт мәгълүмат системасының белешмәләрен, документларын һәм материалларын бирү;

2) шәһәр округының җирле үзидарә органнарының шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә түбәндәге вәкаләтләрен гамәлгә ашыра:

генераль план проектын әзерләү турында карар, шулай ук генераль планга үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерләү турында карар кабул итү;

генераль план проектын әзерләү, генераль планны раслау, шул исәптән генераль планга үзгәрешләр кертү;

территориаль планлаштыруның һәм шәһәр төзелешен зоналаштыруның бердәм документын әзерләү һәм раслау, шул исәптән мондый бердәм документка үзгәрешләр кертү;

җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү турында, шулай ук җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында яисә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәрне кире кагу турында проектны әзерләү хакында карар кабул итү;

җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау, шул исәптән җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү;

шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү һәм раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү, шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен билгеләү;

җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында йә мондый рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү;

рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә йә мондый рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү;

территорияне планлаштыру документларын әзерләү турында карар кабул итү;

территорияне планлаштыру документларын әзерләүне тәэмин итү, территорияне планлаштыру документларын раслау, шул исәптән территорияне планлаштыру документларына үзгәрешләр кертү;

шәһәр округы территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә объектлар төзелешенә, аларны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү;

җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү, теркәү һәм бирү;

территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул итү һәм гамәлгә ашыру;

җир кишәрлекләренә һәм (яисә) аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларына хокук ияләре инициативасы буенча гамәлгә ашырыла торган территорияне комплекслы үстерү турында шартнамәләр төзү;

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә яңадан бүленгән Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системасы вәкаләтләрен алып бару һәм мондый дәүләт мәгълүмат системасының белешмәләрен, документларын һәм материалларын бирү.»;

әлеге карарга теркәлгән 1 нче һәм 2 нче кушымталар үз көчен югалткан дип танырга.

әлеге карарга кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

2. Бу карар, әлеге карарның 1 пунктындагы кырык икенче – илле җиденче абзацларыннан тыш, 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2005 ел, 6 июль, 313 нче
карарына кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 29 декабрь, 1721 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының территориаль органнарындагы
штат саны

| Т/с | Муниципаль район исеме | Штат саны |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Әгерҗе муниципаль районы | 1 |
| 2 | Азнакай муниципаль районы | 1 |
| 3 | Аксубай муниципаль районы | 2 |
| 4 | Актаныш муниципаль районы | 1 |
| 5 | Алексеевск муниципаль районы | 1 |
| 6 | Әлки муниципаль районы | 1 |
| 7 | Әлмәт муниципаль районы | 4 |
| 8 | Апас муниципаль районы | 2 |
| 9 | Арча муниципаль районы | 2 |
| 10 | Әтнә муниципаль районы | 1 |
| 11 | Баулы муниципаль районы | 1 |
| 12 | Балтач муниципаль районы | 1 |
| 13 | Бөгелмә муниципаль районы | 2 |
| 14 | Буа муниципаль районы | 2 |
| 15 | Югары Ослан муниципаль районы | 1 |
| 16 | Биектау муниципаль районы | 1 |
| 17 | Чүпрәле муниципаль районы | 1 |
| 18 | Алабуга муниципаль районы | 4 |
| 19 | Зәй муниципаль районы | 1 |
| 20 | Зеленодольск муниципаль районы | 2 |
| 21 | Кайбыч муниципаль районы | 1 |
| 22 | Кама Тамагы муниципаль районы | 2 |
| 23 | Кукмара муниципаль районы | 2 |
| 24 | Лаеш муниципаль районы | 2 |
| 25 | Лениногорск муниципаль районы | 2 |
| 26 | Мамадыш муниципаль районы | 2 |
| 27 | Менделеевск муниципаль районы | 1 |
| 28 | Минзәлә муниципаль районы | 2 |
| 29 | Мөслим муниципаль районы | 1 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 30 | Яңа Чишмә муниципаль районы | 1 |
| 31 | Түбән Кама муниципаль районы | 2 |
| 32 | Нурлат муниципаль районы | 2 |
| 33 | Питрәч муниципаль районы | 2 |
| 34 | Балык Бистәсе муниципаль районы | 1 |
| 35 | Саба муниципаль районы | 2 |
| 36 | Сарман муниципаль районы | 1 |
| 37 | Спас муниципаль районы | 1 |
| 38 | Тәтеш муниципаль районы | 2 |
| 39 | Тукай муниципаль районы | 1 |
| 40 | Теләче муниципаль районы | 1 |
| 41 | Чирмешән муниципаль районы | 1 |
| 42 | Чистай муниципаль районы | 2 |
| 43 | Ютазы муниципаль районы | 1 |
|  | Барлыгы | 67 |